# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Ялкын авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Гурьевка авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 13 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Ялкын авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гурьевка авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Таарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Ялкын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Гурьевка авыл торак пунктында (торак пункты территориясының өлешендә) яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Гагарин урамында юл төзелеше,
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (кышкы чорда чистарту һәм чабу),
- урамнарны яктыртуны карап тоту,
- су челтәрләрен карап тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Ялкын авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Ялкын авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Ялкын авыл җирлеге башлыгы

____________ **И.В.Гущина**

(имза) (имзаның расшифровкасы)